**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ______________ КАРАР ______

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә тоткарланган транспорт чараларын саклау өчен махсуслаштырылган стоянкага хезмәт күрсәтүне оештыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге131-ФЗ номерлы Федераль законның 14-15 статьясы, «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль законның 2,6 статьясы, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатыннан, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә 2021-2022 еллар чорына юл хәрәкәте өлкәсендә административ хокук бозулар белән бәйле рәвештә тоткарланган транспорт чараларын саклау өчен махсус стоянка хезмәте күрсәтүне оештырырга.

2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә 2021 елдан 2022 елга кадәр, юл хәрәкәте өлкәсендә административ хокук бозуларга бәйле рәвештә тоткарланган транспорт чараларын саклау өчен махсус стоянкага хезмәт күрсәтү хокукына ачык конкурс үткәрү буенча конкурс документациясен (1 нче кушымта) расларга.

3. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә 2021 елдан 2022 елга кадәр махсус стоянка хезмәтләре күрсәтү хокукына ачык конкурс үткәрү, конкурска йомгак ясау буенча конкурс комиссиясе төзергә һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

4. «Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының»Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә тоткарланган транспорт чараларын саклау өчен махсуслаштырылган стоянка хезмәте күрсәтүне оештыру турында "2020 ел, 18 ноябрь, 229 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.И.Габдулхаев

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
2 нче кушымта
___ _________ 2020 ел,№ ПР__

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә 2021елдан 2022 елга кадәр махсуслаштырылган стоянка хезмәтләре күрсәтү хокукына ачык конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Галимҗанова Р.Ф. | Актаныш муниципаль районы башлыгы урынбасары, комиссия рәисе (килешү буенча); |
| Гарипов Р.И. | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Фазлыев Ф.Н. | Башкарма комитетның инфраструктур үсеш бүлеге җитәкчесе, комиссия әгъзасы, - заявкалары булган конвертларны ачу беркетмәсенә 1 нче һәм 2 нче кушымталарны тутыру (алып бару) буенча җаваплы; |
| Галиуллина Л.П. | Актаныш муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе, комиссия члены; |
| Госсамова Р. Г. | «Яран» ТМШ ИК белгече - секретарь (килешү буенча). |

Лист согласования к документу № ПР-265 от 26.12.2020
Инициатор согласования: Салимов Д.З. Начальник юридического отдела
Согласование инициировано: 26.12.2020 14:11

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Габдулхаев И.И. | | Подписано 26.12.2020 - 14:54 | - |